КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 15 апрель г.Казань № 419

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 1 сентябрь, 940 нчы; 2023 ел, 6 март, 212 нче; 2023 ел, 29 май, 652 нче; 2023 ел, 4 август, 945 нче; 2024 ел, 4 октябрь, 854 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктының җиденче абзацындагы «резидентлары һәм идарә итүче

компанияләре» сүзләрен «резидентлары, идарә итүче компанияләре» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта:

3.1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Заявка бирүче турында мәгълүмат:

заявка бирүченең тулы һәм кыскартылган исеме (юридик затлар өчен);

индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

заявка бирүченең төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

муниципаль берәмлекләр территорияләренең гомумроссия классификаторы;

индивидуаль эшкуарның индивидуаль шәхси счеты иминләштерү номеры (СНИЛС);

юридик затның җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), салым түләүченең идентификация номеры, индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС), вазыйфасы);

юридик зат адресы, теркәлү адресы (индивидуаль эшкуарлар өчен);

элемтәгә керү өчен телефон номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

заявка бирүченең тибы (резидент, идарә итүче компания);

субсидия күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүгә кул куюга вәкаләтле зат турында мәгълүмат.»;

3.1.2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

3.2 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унөченче абзацта «биш календарь» сүзләрен «15 эш» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге пунктта билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә заявка бирүчеләрнең заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән заявка бирүчеләр, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы

белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

4.2 пунктның икенче абзацына «(әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы егерме өченче абзацында каралган очрактан тыш)» сүзләрен өстәргә;

4.3 пунктның өченче абзацында «эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «бер эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктта:

беренче абзацта «эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көнлек срок» сүзләрен «15 эш көненнән артмаган срок» сүзләренә алмаштырырга;

өченче һәм унберенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

4.5 пунктның сигезенче абзацында «2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәрле оешмалар челтәрләре буенча электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә бердәм (котел) тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 19 декабрендәге 3-26/э номерлы» сүзләрен «2025 – 2029 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәрле оешмалар челтәрләре буенча электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә бердәм (котел) тарифлар билгеләү турында» 2024 елның 21 ноябрендәге 339-12/э-2024 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

4.6 пунктта:

беренче абзацта «эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «бер эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

5.6 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Бирелгән субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия алучы тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару өчен билгеләнгән срок бозылганда, вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия акчасын кире кайтару буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин